ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

17.11.2024 **Чистай шәһәре** № 538

2025-2027 елларга Чистай муниципаль
районында хокук бозуларны
профилактикалау буенча комплекслы
программаны раслау турында»

Хокук бозуларны, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын профилактикалау системасын ныгыту, бу эшчәнлеккә җирле үзидарә органнарын, иҗтимагый оешмаларны һәм халыкны җәлеп итү, хокук бозуларны профилактикалауда һәм җинаятьчелеккә каршы көрәштә җирле үзидарә органнарының ролен һәм җаваплылыгын арттыру, шулай ук «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы федераль законны, «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 2017 елның 11 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025-2027 елларга Чистай муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча кушымтада бирелә торган комплекслы программаны (алга таба - Программа) расларга.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетына программаның заказчы-координаторы булырга.
3. Чистай муниципаль районының финанс-бюджет палатасына ел саен Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының чираттагы финанс елына бюджетын формалаштырганда Программа чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы бюджетыннан әлеге максатларга юнәлдерелә торган акчаларның мөмкинлекләрен исәпкә алып һәм чикләрендә акчалар карауны тәкъдим итәргә.
4. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 9 ноябрендәге 581 номерлы карарын 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип санарга.

5. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясенә йөкләргә.
7. Әлеге карарны Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru// бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов